# ГАРМУН АЛЫЙК ӘЛЕ, ДУСКАЙ

*Риф Гатауллин көе*
*Габделхак Шакиров шигыре*

Гармун алыйк әле, дускай,
Гармун уйнатыйк әле.
Яшь чактагы көй-моңнарны
Кабат уятыйк әле.

Йөрәкләрне җилкендерсен
Тальянның көмеш чыңы.
Бар яшьләрнең күңеленә
Керсен халкыбыз моңы.

Бабайлар моңыннан башка
Туган җир ятим бит ул.
Көйсеэ-моңсыз үткән көннәр
Яшәлмәгән көн бит ул.